

Мин Раис Каюм улы Вергасов белән кvптәннән район vзәге булган Атюрьево авылынын бер урамында яшим.
Н.П.Огарев исемендәге МГУны тәмамлангач, Кадошкино районында бераз хезмәт итеп алгач, Раис Каюм улы янадан Атюрьево районына кайтты. Авыл хужалыгы идарәсендә техник саклык инженеры, ә 1977нче елдан россельхозуправлениедә баш инженер буларак эшли башлады.
Ничектер Раис Каюм улы Вергасов белән мина, РК КПССнын пропаганда һәм агитация бvлеге инструкторына, бюрога зур сорау әзерләргә туры килде. Кvп тырыштык. Шуннан Раис Каюм улы, дәлилләр белән чыгыш ясады. Анын чыгышы РК КПССнын беренче секретаре В.И.Кабаевка бик тә ошады. Бу чыгыштан сон ул КПСС райкомы кадрлары резервына кертелде. Ә 1982 елны Усть-Рахмановканын «Коммунар» колхозына, колхозчылары жыелышында, Р.К.Вергасовны председатель итеп сайладылар. Ул данлыклы шәхес булган Шәйхулла Исмаил улы Старковнын алмашы иде. Шәйхулла Исмаил улы берничә дистә еллар туган авылы Усть-Рахмановкада «Коммунар» колхозы житәкчесе буларак, малчылык һәм vсемлекчелек буенча алдынгы колхоз дәрәжәсенә кvтәрде. Данлыклы колхозны, vзенен 660 эре мозезлесе, мен баш сарыгы, 3 мен гектар чәчелмәгән жире, ике меннән артык чәчелгән ашлыгы белән кабул итә Раис Каюм улы Вергасов. Кvп тырышырга туры килә. Һәм 1988 елда, булган унышларны vстереп, колхоз эшләре тагы да югарыга vрмәли: эре мозезлесен 1300гә һәм сарыгын 2000 башка кадәр арттыра. Сотләре дә район буенча ин кvп – сыер башыннан 3500 литр савып ала башлыйлар. Шул елларда колхозчыларнын югары зарплаталары да куандырып торды. Шундый темплар белән алга 18 ел атлый «Коммунар» колхозы житәкчесе. Ул халыкны яхшылап ойрәнә, кешеләр белән уртак тел таба белә. Житәкче буларак таләпчән дә һәм шул ук вакытта гадел дә булды: тырышларын бvләкләде, олылырын хормәтли белде. Бvләкләнгәннәр арасында тракторлар бригадасы бригадиры Д.Б.Алтынов, Боек Ватан сугышында катнашкан механизатор Б.З.Иртуганов, машина йортvче Р.А.Иртуганов, сыер савучылар М.А.Байчурина, Г.А.Неверова исемдә калган. Житәкчеләр vзен дә, Р.К.Вергасовны, ирешкән дәрәжәләрен югары бәяләп, «Мордовиянен атказанган авыл хужалыгы хезмәткәре» дигән исем бирделәр. Башка югары бvләкләре һәм грамоталары да кvп анын.
Замана vзгәрде һәм ул да эш урынын vзгәртте. 2000 елдан алып Р.К.Вергасов район администрациясендә оештыру бvлеге модире буларак хезмәтен дәвам итә. Шул вакытта ул, районда бердән-бер буларак, башкалабыз Саранскtан «Юлдаш» газетасын яздырып ала иде. Бу газетаны ул мина укырга биреп килде һәм миннән, Мордовия халкы

Атюрьево районы эшләре турында белсеннәр дип, мәкалә язып жибәрергә кушты. Шулай мин «Юлдаш»ка юлдаш булдым. Әле генә район ветераннары Советында очраттым Раис Каюм улын һәм 2017нче елны ана 70 яшь тулганын исемә тошердем. Хормәткә лаеклы кешенен бу датасы тагы бер тапкыр тормыш баскычларын, хезмәт биографиясен искә алырга сәбәп булды һәм кулыма каләм алдым.
Раис Каюмовичнын балачагындагы эпизодлары кvнеленен тирән почмагына уелып калган. Аралашканда алар турында еш сагына. Хәтердә калганнарынын берсендә: «1954 елны Тvбән Пишләй гомуми топ мәктәбенен беренче сыйныфына укырга киттем. Ул вакыт мәктәптә барлыгы 100 укучы белем ала иде. Ө беренчеләргә 14әv килдек. Хәзер безнен авылда башлангыч мәктәп юк, чонки балалар юк. Кvнелсез кvренеш, чонки Россиянен тамыры нәкъ авылларда яши, нәкъ анда барлык халыкнын милли традицияләре, мәдәнияты. Шәһәр шартларында уртача россиялеләр тәрбияләнә», - дип кайгырткан фикерләре истә.
Бу ирнен тышкы кыяфә-теннән vк сабыр кеше булуы кvренеп тора. Ул куелган максатына ирешер очен бар кочен куя. Улына топ тәрбия кыйммәтләрен әнисе бирде. Ул улын хезмәтне яратырга, һәрвакыт эшне жиренә житкереп башкарырга, алда куелган максатларга ирешергә ойрәтте дә. Р.К.Вергасов белән аралашканда, ул бvген гаилә тәрбиясенен кыйммәтләрен югалтып киләбез, ди. Традиция буенча, гадәти татар гаиләсендә элек биш баладан артыграк була иде. Шул кvпбалалы гаиләдә бер-берен очен жаваплылык, ярдәмчелек тәрбияләнеп килде. Гаиләдә тәрбияләнгән бу кешелеклелек сыйфатлары Раис Каюм улына бар урында унышлы булырга ярдәм итте: гел бишле билгеләренә Стрельников урта мәктәбен тәмамларга, Ватаны сакчысы буларак мактаулы исем яуларга. Шәхси тормышында да унышлы ул. Менә инде 40 ел буена тормыш иптәше Лидия Михайловна (укытучы) белән бергә бәхетлеләр. Алар оч кыз тәрбияләп vстерделәр, югары белем биреп олы тормыш юлына чыгарып жибәрделәр.
Ул таләпчән, әмма гадел, дидем. Yз остендә Раис Каюм улы бvген дә эшли: янадан-яна идеялары булып тора. Халык кинәш очен анын янына килә. Минемчә, теләсә кайсы тормыш ситуациясендә ул дорес юл таба. Шуна да коллегалары, халык аны белә, хормәт итә.

**Владимир Ермишев**